**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**18 ноябрь 2021 ел.** **№2**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Зур Рәс торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

2021 елның 01 декабрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Зур Рәс торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Зур Рәс ав., Күлле ур., 12 йорт янында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

Зур Рәс торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Зур Рәс торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Зур Рәс торак пунктының Күлле урамына вак таш җәюгә юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә..

Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев